| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**14.11.2016** | Зеленодольск ш | **КАРАР**<br>**№ 92** |

2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары С. В. Кадырованың 2017 елның 1 гыйнварыннан Зеленодольск шәһәре территориясендә физик затлар милкенә салым турындагы мәгълүматларын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Федераль законга таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының “Зеленодольск шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә салым салу объектының кадастр бәясеннән чыгып, мәҗбүри түләнергә тиешле физик затлар милкенә салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Салым ставкаларын түбәндәгечә билгеләргә:

1) 0,2% күләмендә:

- торак биналарга (фатир, бүлмә);

2) 0,3% күләмендә:

- һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакча яки шәхси торак төзелеше өчен бирелгән җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмаларына;

- торак йортларга;

-мондый объектларны проектлаштыра торган торак йорт булса, тәмамланмаган төзелеш объектларына;

- составына ким дигәндә бер торак бина (Торак йорт) керә торган бердәм күчемсез комплексларга;

- гаражлар һәм машина урыннара.

3) 2% күләмендә:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларына;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 маддәсендәге 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына;

4) 0,5% күләмендә:

- башка салым салу объектларына.

3. Физик затлар милкенә салымны түләүдән азат итү рәвешендә ташлама билгеләргә:

- ата-аналары яки опекуннары булган физик затларга, алар белән өч һәм аннан да күбрәк бала яшәсә (теркәлгән булса) :

1) балигъ булмаганнарга (18 яшькә кадәр),

2) инвалидларга,

3) белем бирү учреждениеләрендә көндезге уку формасы буенча укучыларга (23 яшькә кадәр),

һәм салым салу объектларына карата милек хокукы булган затларга: бер торак йорт яки бер торак (фатир, бүлмә) һәм бер гараж яки бер машина урыны;

- милекләрендә бер хуҗалык корылмасы яки бер корылмасы булган физик затларга, аларның һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан.

Салым ташламасына хокукы булган зат ташлама бирү турында гариза һәм салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшыра.

4. Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

- Зеленодольск шәһәре Советының 2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы "Физик затлар милкенә салым турында» карарын;

- “2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында” гы Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 12 маендагы 318 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарын

- Зеленодольск шәһәре Советының 2015 елның 10 ноябрендәге 16 номерлы "Физик затлар мөлкәтенә салым турында" карарын “2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында" (2015 елның 12 маендагы 318 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән);

- Зеленодольск шәһәре Советының 2016 елның 15 февралендәге 49 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карары “2014 елның 17 ноябрендәге 293 номерлы Зеленодольск шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында " (үзгәрешләр белән, шәһәр Советының 2015 елның 12 маендагы 318 номерлы, 2015 елның 10 ноябрендәге 16 номерлы карарлары белән кертелгән)».

5. Әлеге карар 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылып чыкканнан соң 1 айдан да иртәрәк түгел.

6. Әлеге карарны "Зеленодольская правда» һәм "Яшел Узен" газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайты (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә урнаштырырга

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**